Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«01» ноябрь 2019 ел №92

Территорияне межалау проектын
әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, территориянең тотрыклы үсешен һәм планлаштыру структурасы элементларын аерып алуны тәэмин итү максатларында, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия тәкъдиме нигезендә, 2019 елның 9 октябрендәге 7964и номерлы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия тәкъдиме нигезендә, Игнатьев Сергей Михайловичның мөрәҗәгате нигезендә,

ӘЛМӘТ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. Игнатьев Сергей Михайловичка үз акчалары исәбеннән территорияне ызанлау проектын , кадастр номеры 16:45:0118:86, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре җирлеге, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр проспекты адресы буенча урнашкан җир кишәрлегенә карата кызыл сызыклар чикләрен билгеләү өлешендә эшкәртүгә керешергә тәкъдим итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе турындагы әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3 Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А. А. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев